**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«28» март, 2018 ел** **№ 207**

**Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2017 елның 30 мартындагы 130 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2017 елның 26 маендагы 149 номерлы Карар редакциясендә)**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының 2017 елның 30 мартындагы 130 номерлы карары белән расланган, Биектау муниципаль районы Советының 2017 елның 26 маендагы 149 номерлы карары белән үзгәрешләр кертелгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге тарафыннан күрсәтелә торган Муниципаль хезмәтләр бүлегенең 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелешкә рөхсәт бирү буенча»,

2) Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге тарафыннан күрсәтелә торган Муниципаль хезмәтләр бүлеген «Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын тигезләп кисүгә яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча» дип аталган 11 пункт белән тулыландырырга;

3) Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге тарафыннан күрсәтелә торган Муниципаль хезмәтләр бүлеген «Муниципаль берәмлек чикләрендә җирле әһәмияттәге юллар буйлап тулысынча яисә өлешчә уза торган маршрутлар буенча авыр үлчәүле йөкләрне, эре габаритлы

йөкләрне автомобильләр белән ташуга рөхсәт бирү буенча» дип аталган 12 пункт белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында http://pravo.tatarstan.ru игълан итәргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г. Кәлимуллин